ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Карар Постановление

« 25 » декабрь, 2025 ел. № 29

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән , 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге

-2025 елның 30 нчы октябрь 1 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Түбән Сон торак пунктында үзара салым кертү турында »;

-2025 елның 30 нчы октябрь 2 нче санлы «Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче Түбән Сон торак пунктында гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»;

-2025 елның 30 нчы октябрь 3 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Колышчы торак пунктында үзара салым кертү турында »;

-2025 елның 30 нчы октябрь 4 нче санлы «Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче Колышчы торак пунктында гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»;

-2025 елның 30 нчы октябрь 5 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Рәхмәт Аланы торак пунктында үзара салым кертү турында »;

-2025 елның 30 нчы октябрь 6 нчы санлы «Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге составына керүче Рәхмәт Аланы торак пунктында

гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»;гы карарлар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:
:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Ш.Гафиятуллин

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.12. 2025 ел,24 нче санлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2026 елның 25 нче мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт

хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25 нчы декабрь, 2025 ел,
24 нче санлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш Муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең Түбән Сон авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2026 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 25.03.2026 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ____сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Мамадышского муниципального района РТ)

Кабул итүче як банкы
Сч. №
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН
КПП
КБК
ОКТМО
Түләүнең билгеләнеше: Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче __________________ ________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

___________________________________________________________________

(*муниципаль берәмлек исеме)*

_________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № __________________
Түләүченең Ф.И.Ә.и.

___________________________________________________________________

Адрес:

___________________________________________________________________

«__» ________________ 20__ г. ________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)*____________________
*авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*